Республика Татарстан
САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 сентябрь 2022 ел №122

Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының 06.04.2020 ел №76 карары белән расланган Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 ел, №1081 РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының “Саба шәһәр җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 6 апрелендәге 76 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1.3 пунктында «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 3.3 пунктның икенче абзацында «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3.3 пунктның өченче абзацын киләсе редакциядә бәян итергә:

"бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы, ул ташламаларга хокуклы түләүчеләр саны нисбәте һәм ташламаларны куллану хокукына ия булган түләүчеләр саны яки 5 еллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов